КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 октябрь г.Казань № 888

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Программаның дәүләт заказчысы – координаторы итеп Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда, мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм бу максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә Программа чараларын гамәлгә ашыруга акчаларны күздә тотарга.

4. Әлеге карар, әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә торган 3 пункттан тыш, 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны бирелгән вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин